РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» октябрь 2016ел. Буа шәһәре № 115

**«Буа муниципаль районында Террорчылыкка каршы комиссия нигезләмәсе турында» Буа муниципаль районы Башлыгының 2012 елның 28 декабрендәге 69 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районында Террорчылыкка каршы комиссия нигезләмәсенә үзгәреш кертү хакында»**

Буа муниципаль районында Террорчылыкка каршы комиссия составындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Буа муниципаль районы Башлыгының «Буа муниципаль районында Террорчылыкка каршы көрәш комиссиясе нигезләмәсе турында» 2003 елның 28 декабрендәге 69 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районында Террорчылыкка каршы комиссия нигезләмәсенең 6 пунктындагы 1 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).
2. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru), «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында районның рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы А.К. Айзетуллов

Буа муниципаль районы башлыгының
2012 елның 28 декабрендәге
69 номерлы карарына 1 нче кушымта
(Буа муниципаль районы башлыгының
2016 елның « 11 » октябрендәге
115 номерлы карары редакциясендә)

«6. Вазыйфалар буенча комиссия составына керәләр:

Зеленодольск шәһәрендә РФ ФҖХ ТР буенча бүлеге хезмәткәре, комиссия рәисе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; комиссия рәисе урынбасары;

Буа муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары;

Буа районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы башлыгы, эчке хезмәт подполковнигы, комиссия рәисе урынбасары;

Буа муниципаль районы Советы аппаратының юридик бүлеге баш белгече, комиссия секретаре;

«ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең 8 янгын-коткару отрядының 111 янгын-коткару часте» башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы»;

Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең Буа районындагы һәм Буа шәһәрендәге территориаль бүлеге башлыгы;

Буа муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе;

«Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы- Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары»;

«Буа муниципаль районының Мәдәният идарәсе» МКУ башлыгы;

«Буа муниципаль районының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм идарәсе» МКУ башлыгы;

Россия Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Буа районындагы бүлеге җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы;

Буа шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе;

«Буа АТП» ААҖ генераль директоры;

Татарстан Республикасы буенча хәрби комиссариатның Буа районы буенча бүлеге башлыгы;

«Буа шәһәре идарәче компаниясе» ҖЧҖ генераль директоры;

«Татмедиа» АҖ филиалы директоры, «Байрак» газетасы редакциясе («Байрак», «Ялав»).